ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ МӘКТӘПЛӘР ӨЧЕН АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

10 000 нән артык сүз

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2013

УДК 811.512.145(038)
ББК 81.2Тат-4 я72
Т23

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Гыйльми советы карары нигезендә басыла.

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

Редколлегия:

Ф. Ф. ГАФФАРОВА (фәнни мөхәррир),
Ф. Ә. ГАНИЕВ, Г. Г. САБЕРОВА

Махсус мөхәррире: филология фәннәре докторы, профессор Ф. С. ХӘКИМҖАНОВ

Рецензентлары:

филология фәннәре докторы, профессор Д. Б. РАМАЗАНОВА;
филология фәннәре докторы, профессор Ф. М. ХИСАМОВА

Т23 **Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге.** – Казан : Татар. кит. нәшр., 2013. – 510 б.
ISBN 978-5-298-02552-2

«Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» мәктәп укытучылары һәм укучылары өчен гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә. Сүзлеккә барлыгы 10 меңнән артык сүз кертелде. Ул татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасыннан һәм фразеологиясеннән, укыту предметларының төп төшенчәләре күләмендә термин һәм атамалардан гыйбарәт. Бу сүзлектән югары уку йорты студентлары да файдалана алачак, матбугат, радио, телевидение хезмәткәрләре, тәрҗемәчеләр өчен дә ул кулай белешмә булып хезмәт итәр. Сүзлек – татар телен өйрәнергә теләүчеләр өчен ярдәмлек кулланма. Төрки телләрне чагыштырып өйрәнүчеләр өчен тикшерү материалы буларак та файдалы чыганак.

УДК 811.512.145(038)
ББК 81.2Тат-4 я72

ISBN 978-5-298-02552-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2013
© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2013

# СҮЗ БАШЫ

Татар теленең сүзләрен җыеп теркәү эше, татар лексикографиясенең башлангычы – бик күптәннән, борынгы төрки телләр сүзлекләре Мәхмүд Кашгари (XI йөз), Ибне Мөһанна (XIII йөз), Әб-эл Хайян Гарнатый (XIV йөз) кебек атаклы тел белгечләре төзеп калдырган хезмәтләрдән килә. Татар лексикографиясенең үз тарихы XVI йөз ахыры – XVII йөз башы кульязма сүзлекләрдән башланып китә.

Татар теленең тулы сүзлеген төзү идеясе беренче тапкыр Казан университеты профессоры Ф. И. Эрдман тарафыннан 1829 елда тәкъдим ителә. Ул аның 12 параграфтан торган программасын эшли. Программада татар сүзләренең рус һәм латин телләренә тәрҗемәсе күздә тотылган була. Ягъни әлеге хезмәт өч телле тәрҗемә сүзлек буларак планлаштырыла. Әмма аңа булган ихтыяҗ 1833, 1835 елларда А. Троянскийның ике кисәктән торган «Словарь татарского языка и некоторых употребительных в нём речений арабских и персидских» дигән сүзлеге басылып чыгу белән бетә. Гомумән алганда, XIX йөз, XX йөз башы татар халкына карата башка халыкларда кызыксыну көчәю белән үзенчәлекле. И. Гиганов, К. Насыйри, Н. Остроумов, М. Юнысов, С. Рахманкулов һ. б. белгечләрнең күп санлы басма тәрҗемә сүзлекләре чыгу шуның нәтиҗәсе булып тора.

Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге «Ләһҗәи татари» күренекле мәгърифәтче һәм галим Каюм Насыйри тарафыннан 1895–1896 елларда ике томда бастырып чыгарыла. Ул 20 меңгә якын сүзне эченә ала. Сүзлек гарәп һәм фарсы телләреннән кергән сүзләрнең татарча мәгънәсен аңлату, татар сүзләренең гарәпчә һәм фарсыча вариантларын китерү, аларның нинди сүзтезмәләрдә кулланылуын күрсәтү тәртибендә эшләнгән.

XX йөзнең беренче чиреге язма әдәби телнең гаять чуар булуы белән үзенчәлекле. Аеруча 1905, 1917 елгы революцияләр чоры телдә зур үзгәрешләр китереп чыгара. Төрек, гарәп, фарсы сүзләре белән чуарланган иске татар әдәби теле сөйләм теленнән ерак булуы белән аерылып тора, гади халыкка авыр аңлашыла. Революцияләр чорында сөйләм теленең тәрҗемәдә киң кулланылуы, әдәбиятка яңа буын каләм ияләре килү татар теленең сүзлек составында зур үзгәрешләр килеп чыгуга сәбәпче була. Шул чор иҗатында әдәби телнең берничә варианты барлыкка килә. Телдә рус теленнән кергән алынмалар күбәя, язма тел халыкның җанлы сөйләм теленә якыная, кайбер сүзләрнең язылышында үзгәрешләр барлыкка килә. Элек «урамча» дип саналган сүзләр һәм грамматик формалар телдә тулы хокук ала. Кыска гына вакыт эчендә тел ике дәвер теленә әверелә. Газета-журнал битләрендә әдәби телнең кайсы вариантын куллану урынлы булуы хакында кызу бәхәсләр кузгала. Шушы сәбәпләр дәвер ихтыяҗын чагылдыра алырлык яңа сүзлек төзү бурычын тудыра.

Шундый буталчык заманда күренекле галим Җамал Вәлиди татар теленең аңлатмалы тулы сүзлеген төзү бурычын үз өстенә ала. Ул әдәби тел эшләнү дәверендә халыкта йөргән, аерым шивәләрдә генә кулланылган барлык сүзләрнең дә сүзлектә теркәлүе гаять мөһим булуын аңлап эш итә. Аның 1927, 1929 елларда басылып чыккан «Татар теленең тулы сүзлеге» гарәп графикасының өч хәрефен – *әлиф, би, ти* хәрефләрен – эченә ала. Кириллицага күчерсәк, сүзлек *әлиф* белән башланган А, Э, Ы, У, Ү, О, Ө, Ә, И хәрефләренә, *би* белән Б, П, *ти* белән Т хәрефләренә төзелә.

Җамал Вәлиди сүзлек төзү бурычы белән генә чикләнми, ул татар лексикографиясенең теориясен дә эшләп чыга һәм беренче тапкыр татар лексикографиясен эзлекле фәнни нигезгә кора. Галим, сүзлекнең сүзлекчәсен туплаганда, биреләчәк сүзләрне лексик һәм грамматик мәгънәләргә бүлеп карауны шарт итеп куя. Ул бары аерым лексик мәгънә белдергән сүзләрне генә сүзлеккә теркәргә мөмкин дип басым ясый. Фигыльләр бирелешенә дә аерым тукталып китә. Аларның юнәлеш формаларын, сүзлектә тулысынча күрсәтеп, төп фигыль аша аңлату кирәклеген әйтә. Кайбер юнәлеш кушымчасы алган фигыльләрнең мөстәкыйль мәгънә белдерүенә дә игътибар итә. Сүзлектә бу мәгънәләрне аерым күрсәтү кирәклегенә басым ясый. Җамал Вәлиди беренче тапкыр, борынгы *-мак* формасыннан баш тартып, сүзлектә теркәү өчен, сөйләм теленнән *-у* (*уку*) кушымчалы исем фигыльләрне төп форма итеп ала. Картотека җыю эшен башлап җибәрә. Бүгенге көндә дә татар лексикографиясе шушы принципларга нигезләнеп эш итә. Ни кызганыч, сүзлек, авторның әйтүенчә, 1925 елда төзелеп беткән булса да, тулысынча басыла алмый кала. Мәгълүм булганча, галим хаксызга репрессияләнә, сүзлекнең калган материалы кулга алына һәм юкка чыгарыла.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н төзү эше 1950 елларда Тел, әдәбият һәм тарих институтында Г. С. Әмиров җитәкчелегендә лексикография бүлеге ачылгач кына яңадан торгызыла. Бүлектә иң башта классик һәм күренекле язучыларның әсәрләреннән, башка төр әдәбияттан лексик материал һәм иллюстрация туплау башлана, картотека базасы булдырыла. Бу эшкә җәмәгатьчелек тәртибендә Татарстан, Башкортстан республикалары, Пермь, Ульяновск, Куйбышев өлкәләре татар мәктәпләренең укучылары һәм укытучылары җәлеп ителә. Һәм шул материалга таянып, өчтомлык аңлатмалы сүзлек төзелә, ул 1977–1981 елларда басылып чыга.

Татар теленең җыйнак, оператив, файдалану өчен уңай булуы белән аерылып торган бертомлык аңлатмалы сүзлеге, яңа авторлар коллективы тарафыннан төзелеп, 2005 елда дөнья күрә. Әлеге сүзлек үзенең эчтәлеге белән киң җәмәгатьчелеккә юнәлтелгән, барлык катлау укучыларга тәкъдим ителә.

Хәзерге вакытта, мәктәптә куллану өчен уңайлы итеп, татар теленең күләм ягыннан кыскарак аңлатмалы сүзлеген төзү бурычы килеп басты. Мәктәпләр өчен тәкъдим ителгән бу аңлатмалы сүзлек беренче тәҗрибә булып тора.

Укучыга татар телен өйрәнү-өйрәтү, туган телне үзләштерүдә белемен тирәнәйтү өчен, мәктәп программасы күләмендә ана телендә материал бирү тәкъдим ителгән сүзлекнең төп максатын билгели. Әлеге сүзлек татар мәктәпләрендә татар телендә мәгълүмат алу чыганагы буларак та каралды. Укыту предметларының төп төшенчәләре күләмендә тәкъдим ителгән терминнар һәм атамаларның (*зоологик, ботаник, химик, физик, лингвистик* һ. б.) бирелешендә фәнни мәгълүматлар берникадәр киңрәк китерелде. Төшенчәләрнең классификациясенә игътибар ителде, аңлатмалар мәктәп программасына туры китереп төзелде. Хәзерге милли яңарыш, гореф-гадәтләребезне барлау, торгызу, динебезгә кире кайту чорында милли традицияләр, уен-бәйрәмнәр, дини эчтәлектәге атамалар теркәлүе белән әлеге сүзлек халыкта зур кызыксыну уятыр дип уйлыйбыз. Биредә мондый төр атамаларга киңрәк урын бирү дә шул ихтыяҗдан чыгып эшләнде. Бу сүзлектә сүзләрне сайлау һәм күп мәгънәле сүзләрнең мәгънәләрен ачыклау, синонимнарын билгеләү, синонимнарның тәңгәллек дәрәҗәсен күрсәтү, аерым очракларда рус теленә тәрҗемәләрен, антонимнарын китерү, сүзләргә грамматик характеристика бирү, сүзләрнең кулланыш үзенчәлекләрен күрсәтү югарыда әйтелгән максатлардан чыгып эшләнде. Алдагылардан үзгә буларак, бу сүзлектә дәрәҗә белдерә торган тезмә фигыльләргә аңлатмалар бирелде. Мәктәп укучылары өчен әлеге хезмәт сүзләрнең мәгънәсен дөрес аңларга, аларны дөрес кулланырга, сүзләрнең аерым грамматик формаларын дөрес ясарга, басымны дөрес куярга һәм сүзләрне дөрес язарга ярдәм итә торган белешмә булачак.

Сүзлеккә барлыгы 10 меңнән артык сүз теркәлде. Ул татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасыннан һәм фразеологиясеннән, укыту предметларының төп төшенчәләрен белдергән термин һәм атамалардан гыйбарәт. Сүзлекне төзүдә татар тел белеменең казанышларына, аның лексикографиясенең бай традициясенә таянылды. Төрки телләрнең, рус теленең һәм башка телләрнең уңай лексикографик тәҗрибәсе исәпкә алынды.

«Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы, профессор Ф. Ә. Ганиев төзегән инструкция нигезендә башкарылды.

Сүзлекне төзүдә **катнаштылар**: *Г. Р. Самирханова* – А, Ө, Ф хәрефләре; *Г. Г. Саберова* – Ә, Ж, З, И, Й, М, Р хәрефләре; *Л. Г. Габдрахманова* – Б, П, Х, Э хәрефләре; *А. Ф. Гайнетдинова* – В, Җ, К («көч» сүзеннән «көянтәчиләк» сүзенә кадәр; «күәс» сүзеннән «күшегү» сүзенә кадәр), Һ, Ц, Ю хәрефләре; *Ф. И. Таһирова* – Г, Д, Е, С, Ы хәрефләре; *А. Р. Рәхимова* – К («каба» сүзеннән «континент» сүзенә кадәр; «коңгыз» сүзеннән «коңгыртлану» сүзенә кадәр; «көбелә» сүзеннән «көфер» сүзенә кадәр; «краб» сүзеннән «куян» сүзенә кадәр; «кыбырсык» сүзеннән «кяфер» сүзенә кадәр); *Ә. Х. Алиева* – К хәрефе («контора» сүзеннән «кояштыр» сүзенә кадәр); *Ф. М. Газизова* – Л хәрефе; *Л. Ш. Шәмсетдинова* – Н, Ү хәрефләре; *Р. Р. Абдуллина* – О, Т, У, Я хәрефләре; *Ф. Ф. Гаффарова* – Ч, Ш, Щ хәрефләре. Сүзлекне техник редакцияләүдә, нәшриятка әзерләүдә В. А. Габдрахманова, О. Н. Галимова, И. И. Сабитова һәм Р. Т. Сәфәров катнашты. «Татар теленең морфологиясе турында кыскача белешмә», «Татар телендә сүзләрнең структурасы һәм сүзьясалышы» кушымталарын – Ф. Ә. Ганиев, «Сүз башы», «Сүзлекнең төзелеше», «Файдаланылган сүзлекләр исемлеге» өлешләрен Ф. Ф. Гаффарова эшләде.

Сүзлекне **редакцияләделәр**:

*Ф. Ә. Ганиев* – А, Б (башыннан алып «бишбармак» сүзенә кадәр), В, Г, Д, Е, К («контора» сүзеннән «көфер» сүзенә кадәр; «краб» сүзеннән «куян» сүзенә кадәр; «кыбырсык» сүзеннән «кяфер» сүзенә кадәр), Н, С, Ү, Ч, Ы хәрефләрен;

*Г. Г. Саберова* – Ә, Ж, Җ, З, И, Й, Л, М, Р, С, Т, У, Ф, Һ, Э хәрефләрен;

*Ф. Ф. Гаффарова* сүзлекне тулысынча редакцияләде.

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

§1. Сүзлектә баш сүзләр үзләренә караган материал белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итә.

§2. Сүзлек мәкаләсе түбәндәге материаллардан тора:

1) баш сүз;

2) сүзнең грамматик формалары ясалышы турында мәгълүмат;

3) грамматик белешмә;

4) стилистик белешмә;

5) сүз мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатма;

6) мисаллар;

7) турыпочмаклык (□) билгесеннән соң беренче сүз тәртибе белән китерелгән, компонентлары аерым язылган кушма сүзләр яки тезмә фигыльләр;

8) кушма сүзләрнең, тезмә фигыльләрнең мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатма;

9) ромб (◊) билгесеннән соң килгән фразеологик берәмлекләрнең мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатма.

§3. Баш сүзләр сүзлектә алфавит тәртибендә урнаштырылды, ярымкалын баш хәрефләр белән китерелде.

§4. Сүзлек гамәлдәге орфография нигезендә эшләнде. Сүзнең телдә вариантлылык очраклары күзәтелсә, сүзлектә аның әдәби телдә актив кулланылган бер варианты гына бирелде. Бары аерым очракларда гына (сүзнең вариантлары телдә киң таралган булса) аларның икесе дә сүзлектә теркәлде:

**АЗ** (-рак) *рәв.* ...

**ӘЗ** (-рәк) *рәв. сөйл. к.* **аз.**

§5. Әгәр дә баш сүз татар телендә аерым кулланылмаса, ул сүздән соң ике нокта куелды, аннан шул сүз кергән гыйбарә китерелде һәм аңа аңлатма бирелде:

**КӨЗӘН** II: **көзән җыеру** Мускулларның үзеннән-үзе тартышып, авырттырып кыскаруы.

**ЮШ: юш килү (булу)** Дөрескә, чынбарлыкка туры килү.

§6. Татар телендә, кагыйдә буларак, басым сүзнең ахыргы иҗегенә төшә, бу очракта баш сүз итеп бирелгән татар сүзләренә басым куелмады. Әгәр дә басым башка иҗеккә төшсә, ул вакытта басым билгесе куелды:

**ЧӨ́НКИ** *терк.* ...

**А́РКА** I (-га; -дан; -сы) *ис.* ...

**АРКА** II (-га; -дан; -сы) *ис.* ...

**АРА́-ТИРӘ** *рәв.* ...

**КӨ́НЬЯК-КӨНБАТЫШ** (-ка; -тан; -ы) *ис.* ...

§7. Бу кагыйдә алынма сүзләргә дә карый:

**ВА́ЗА** (-га; -дан; -сы) *ис.* ...

§8. Төрләнә торган сүз төркемнәренә караган сүзләрнең форма ясалышы турында иң актив кушымчаларны күрсәтү юлы белән билгеле бер дәрәҗәдә мәгълүмат бирелде. Бу мәгълүмат баш сүз артыннан гади җәя эчендә күрсәтелде. Сүзнең үзгәрә торган өлеше вертикаль сызык белән аерылды. Баш сүздән соң гадәти шрифтта гади җәя эчендә исемнәрнең берлек сандагы юнәлеш һәм чыгыш килеше кушымчасы һәм III зат тартым кушымчасы күрсәтелде, фигыльләрдә боерык фигыль формасының берлек сандагы II зат кушымчасы һәм хәзерге заман формасының берлек сандагы III зат кушымчасы китерелде, чагыштыру дәрәҗәсенә ия булган сыйфатларда һәм кайбер рәвешләрдә чагыштыру дәрәҗәсе кушымчасы бирелде:

**ЗАРУРЛЫ|К** (-кка; -ктан; -гы) *ис.* 1) Кирәклек, зарур булу...

**НАЗЛ|А́У** (-а; -ый) *фг.* Иркәләү, кадерләү; якын итепярату...

**АВЫР** (-рак) *сф.* 1) Авырлыгы зур булган, зур үлчәүле...

§9. Татар телендә һәм, гомумән, төрки телләрдә фигыльнең нигезе берлек сандагы II зат боерык фигыль белән тәңгәл килә. Шул сәбәпле, вертикаль сызык белән аерылган өлеш фигыльнең нигезенә туры килгән очракларда, боерык фигыльнең берлектәге II зат формасы сүзлектә аерым күрсәтелмәде:

**БАР|У** (-а) *фг.* ...

§10. «К» һәм «п» хәрефләренә тәмамланган исемнәр тартым белән төрләнгәндә, сузык авазлар янында яңгыраулаша, ә сузык аваз янындагы [йә] дифтонгы, [у] сузыгы [в] тартыгы белән чиратлаша. Сүзлектә бу күренеш «к», «п», «й» һәм «у» хәрефләре алдыннан вертикаль сызык кую һәм гади җәяләр эчендә сызыкча артыннан аларның чиратлашкан ишләрен һәм тартым кушымчасын китерү юлы белән күрсәтелде:

**ЗАТЛЫЛЫ|К** (-кка; -ктан; -гы) *ис.* ...

**КИТА|П** (-пка; -птан; -бы) *ис.* ...

**МАЛАХА|Й** (-йга; -йдан; -е) *ис.* ...

**БУЯ́|У** II (-уга; -удан; -вы) *ис.* ...

§11. Омонимнар һәрберсе аерым сүзлек мәкаләсе итеп бирелде һәм рим цифрлары белән күрсәтелде:

**САН** I (-га; -нан; -ы) *ис.* 1) Санау-хисаплау өчен кулланыла торган микъдар төшенчәсе; математик зурлык...

**САН** II (-га; -нан; -ы) *ис.* Хөрмәт, кадер, ихтирам...

**САН** III (-га; -нан; -ы) *ис. сөйл.* Гәүдәнең бер өлеше яки, гомумән, гәүдә...

§12. Баш сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы грамматик билгеләр белән күрсәтелде: *ис.* (исем), *фг.* (фигыль), *сф.* (сыйфат), *алм.* (алмашлык), *сан* (сан), *рәв.* (рәвеш), *бәйл.* (бәйлек), *терк.* (теркәгеч), *кис.* (кисәкчә), *ымл.* (ымлык), *иярт.* (ияртем), *хәб. сүз* (хәбәрлек сүз), *мод. сүз* (модаль сүз).

§13. Татар телендә бер сүз төркеменә караган сүзләр икенче сүз төркеме мәгънәсендә кулланыла ала. Сүзлектә бу күренеш нокталы ярымкалын гарәп цифры белән аерып күрсәтелде:

**МАКТАНЧЫ|К** (-грак) *сф.* **1.** Мактанырга яратучан, масаючан, шапырынучан. **2.** *ис. мәгъ.* Мактанырга ярата торган кеше.

**САКЛЫ|К** (-кка; -ктан; -гы) *ис.* **1.** 1) Сизгерлек, абайлык, уяулык; 2) Куркынычсызлык, иминлек; 3) *күч.* Сакчыллык. **2.** *сф. мәгъ.* Запаска калдырылган, саклауга салынган.

**ЗАТЛЫ** *сф.* **1.** 1) Яхшы нәселдән булган, нәселле, асыл заттан. *Затлы гаилә*; 2) Яхшы токымлы, махсус үрчетелгән. *Затлы юртак*; 3) Югары бәяле, сыйфаты яхшы булган, кыйммәтле. *Затлы мамык шәл.* **2.** *рәв. мәгъ.* Килешле, яхшы итеп. *Затлы киенү.*

§14. Кайбер мөстәкыйль сүзләрнең ярдәмлек мәгънәсендә килүе дә сүзлектә күрсәтелде:

**БӘЛЕШ** I (-кә; -тән; -е) *ис.* Төрле эчлекле камыр ризыгы. *Алма бәлеше.*

**БӘ́ЛЕШ** II *ымл.* Гаҗәпләнүне белдерә. *Бәлеш, син дә килдеңмени?*

**ЭЧ** (-кә; -тән; -е) *ис.* **1.** 1) Кеше һәм хайван гәүдәсенең бавыр, ашказаны, талак, эчәкләр, бөер урнашкан өлеше; корсак. *Эчем авырта*; 2) Нәрсә белән булса да ябылган, капланган, бөркәлгән урын. *Йорт эче якты һәм җылы*; 3) Эчке якка тегелгән материал, кием эчлеге. *Тун эче*; 4) Күңел, йөрәк. *Аның шатлыгы эченә сыймый.* **2. эчендә** *бәйл. сүз мәгъ.* 1) Предмет яки зат урнашкан урынны яки эш-хәл башкарыла торган җирне белдерү өчен кулланыла. *Өй эчендә ыгы-зыгы купты*; 2) Арасында. *Бер сәгать эчендә эшләп бетерде*; 3) Эш башкарыла торган мохитне белдерә. *Тормыш эчендә кайнау.*

§15. Грамматик мәгънә белдерә торган фигыльләрнең саф юнәлеш формалары телнең грамматик төзелешенә карый, һәм алар сүзлектә теркәлмәде.

§16. Лексик мәгънәгә ия булган фигыльләрнең юнәлеш формалары сүзлектә бирелде. Аларның беренче грамматик мәгънәсе төп формага җибәрү юлы белән күрсәтелде, ә лексик мәгънәсенә (мәгънәләренә) аңлатмалар китерелде:

**ЮЫЛ|У** (-а) *фг.* 1) *төш. юн. к.* **юу**. *Урын-җир чиста юылган*; 2) Билгеле бер тышкы тәэсирләр нәтиҗәсендә ашалу яки уну. *Буявы юылу.*

§17. Сыйфат фигыль һәм хәл фигыль формалары грамматик категория буларак сүзлектә аерым китерелми. Әмма кайбер вакытта алар төп фигыльдән үзгә сыйфат һәм рәвеш мәгънәләрен дә белдерергә мөмкин. Бу очракта төп сүзнең барлык мәгънәләренә дә аңлатма биреп бетергәч, нокталы ярымкалын гарәп цифрыннан соң алар аерым күрсәтелеп теркәлде һәм лексик мәгънәләре аңлатылды:

**ВАКЛ|А́У** (-а; -ый) *фг.* **1.** 1) Вак кисәкләргә бүлгәләү. *Утын ваклау*; 2) Эре акчаны шул ук суммадагы awrak акчаларга алмаштыру; акчаны вакка әйләндерү. *Меңлекне ваклау.* **2. ваклап** *рәв. мәгъ.* 1) Аз-азлап, бүлгәләп, бүлә-бүлә. *Ваклап сату*; 2) Төпченеп, җентекләп. *Ваклап сорашу.*

§18. Татар телендә кайбер мөстәкыйль фигыльләр ярдәмче фигыль функциясендә йөри. Сүзлектә бу күренеш күрсәтелде:

**КИТ|Ү** I (-ә) *фг.* **1.** 1) ... ; 2) ... . **2.** *ярд. фг. функ.* 1) Юнәлеш килешендәге кайбер исем, сыйфат, рәвешләр белән килеп, шулардан аңлашылган торыш, билге һәм рәвешкә күчүне белдерә. *Эшләр уңайга китте*; 2) Эш-хәлнең кинәт булуын белдерә. *Тазарып киткән*; 3) Эшнең башка бер эш уңаенда кыска гына аралыкта булуын белдерә. *Таныштырып китү*; 4) Эшнең башлануын һәм дәвам итүен белдерә. *Санап китү.*

§19. Төрле халык вәкилләренең исемнәре чикләнгән күләмдә генә бирелде:

**АБХАЗ** (-га; -дан; -ы) *ис.* Телләре кавказ телләре төркеменә караган, Абхазиянең төп халкы атамасы (үзатамалары – *апсуа*) һәм шул халыкның бер кешесе. *Абхаз теле.*

§20. Сүзлек мәкаләсендә зат алмашлыкларының һәм «ул», «бу», «шул» алмашлыкларының кыек килеш формалары да бирелде. Ул баш сүз артыннан гади җәя эчендә күрсәтелде. Сүзнең нигезе үзгәргән очраклар аерым сүзлек мәкаләсе итеп китерелде:

**МИН** (минем, миңа, мине, миннән, миндә) *алм.* Сөйләүченең үзен атап күрсәтү өчен кулланыла торган беренче зат алмашлыгы...

**УЛ** II (аның, аңа, аны, аннан, анда) *алм.* **1.** 1) Өченче затны яисә, гомумән, предметны белдерә; 2) Исемнәрне ачыклаган сүзне алмаштырып килә торган күрсәтү алмашлыгы: андый, мондый, шундый...

**АҢА** *алм.* «Ул» алмашлыгының юнәлеш килеш формасы.

§21. Татар теле лексикасының шактый өлеше стилистик яктан нейтраль, ягъни сөйләм һәм язма телнең теләсә нинди өлкәсендә бернинди стилистик төсмерсез кулланыла ала. Шуның белән бергә, әдәби телдәге сүзләрнең бер өлеше стилистик яктан битараф түгелләр, төрле стильләргә карыйлар. Сүзлектә андый сүзләрнең кайсы стильгә каравы аерым билгеләр белән күрсәтелде:

**МАЙМЫЛ** (-га; -дан; -ы) *ис.* 1) ... ; 2) *күч. сөйл.* Кеше үчекләүче, кыланчык кеше; 3) *күч. сөйл.* Маймылга охшаган, шыксыз, кыяфәтсез кеше.

**ЗАҺИД** (-ка; -тан; -ы) *ис. иск. кит.* Суфи, диндар кеше.

**ЕРТЫ́ЛГАНЧЫ** *рәв. гади с.* Чамадан тыш. *Тамагы ертылганчы кычкыру.*

§22. Сүзлектә сүзнең мәгънәсе өч юл белән аңлатылды:

1) тасвирый аңлатма;

2) сүзнең мәгънәсен синонимнар ярдәмендә ачыклау;

3) сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аны икенче сүзгә җибәрү.

§23. Сүзнең мәгънәсе күпчелек очракта билгеләмә (аңлатма) бирү юлы белән аңлатылды.

§24. Аңлатмалар баш хәреф белән башланып китте. Сүзнең әдәби телдә урнашкан һәм хәзерге телдә актив кулланыла торган мәгънәләре генә китерелде; кайбер очрак-

ларда тасвирый аңлатмалар синонимнар белән дә тулыландырылды:

**НАЗ** (-га; -дан; -ы) *ис.* 1) Иркә, йомшак мөнәсәбәт, игътибар. *Ана назы*; 2) Көйсезлек, кирелек, каприз. *Кызның чираттагы назы.*

§25. Индивидуаль, метафорик, шигъри мәгънәләргә, шулай ук аларның чагыштыруларда очрый торган мәгънәләренә аңлатмалар бирелмәде. Сүзләрдәге мондый мәгънәләр кайбер очракларда гына мисалларда күрсәтелде.

§26. Күп мәгънәле сүзләрнең аерым мәгънәләре җәя куелган гарәп цифрларыннан соң тоташ текст белән бирелде; мәгънә төсмерләре шул ук мәгънә эчендә нокталы өтер белән аерылды.

§27. Кайбер очракта, сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен, аның синонимына яки аерым мәгънәләренә җибәрелде. Бу юл синонимнарның тәңгәллек дәрәҗәсен дә күрсәтә ала.

**ШИКЕЛЛЕ** *бәйл.* 1) Сыйфат яки күләм ягыннан чагыштыруны яки охшатуны аңлата; төсле, кебек, сыман. *Баг алмасы шикелле алсу йөзле;* 2) Бик төгәл белмичә, икеләнеп әйтүне белдерә; кебек, бугай. *Хәтерем ялгышмаса, килсен дип әйтте шикелле*; 3) Уртак үзенчәлекләре булган охшаш предметларның барысын да санап китмичә, бер-икесен атап, шулар аша башкаларының да булуын аңлату өчен кулланыла; шулар ише. *Суган, кишер, чөгендер шикелле яшелчәләр*.

**ТӨСЛЕ** II *бәйл. к.* **шикелле** (1 мәгъ.). *Әнисе төсле уңган.*

**КЕБЕК** *бәйл. к.* **шикелле**. *Йолдыз кебек җемелдәү.*

§28. Мәгънәләре охшаш яки бик якын булган сүзләрдә (синонимнарда) төп аңлатма тиңдәшләренә караганда күбрәк кулланыла торган сүз янында бирелде, ә калганнарының мәгънәсе шул сүзгә җибәрү юлы белән ачыкланды:

**ЯРА** (-га; -дан; -сы) *ис.* Тән тиресенең бөтенлеге бозылган урын, җәрәхәт. *Яраны бәйләү.*

**ҖӘРӘХӘТ** (-кә; -тән; -е) *ис.* 1) *к.* **яра**. *Үлекле җәрәхәт*; 2) ...

§29. Әгәр дә сүзнең мәгънәсе күп мәгънәле сүзгә җибәрү юлы белән аңлатылса, аның кайсы мәгънәсенә җибәрелүе күрсәтелде:

**БӘҺА** (-гә; -дән; -се) *ис. иск.* **бәя 1** (1, 4 мәгъ.).

§30. Махсус атамаларны, терминнарны биргәндә, соңгы вакытта активлашып киткән сүзләрдә аларның русча тәрҗемәләре дә китерелде:

**ҖӘЕН** I (-гә; -нән; -е) *ис.* Җәенсыманнар семьялыгына караган, авыз тирәсендә өч пар мыегы булган, киң зур башлы, тәңкәсез шома тәнле, су төбендә яшәүче, бака һ. б. вак су хайваннары белән туклана торган зур ерткыч балык; *русчасы*: **сом**.

**ЮЛЛАМА** (-га; -дан; -сы) *ис.* Берәр кешене кая да булса җибәрүне белдергән рәсми документ; *русчасы*: **путёвка**.

§31. Сүзнең мәгънәсенә аңлатма биргәннән соң, курсив ярдәмендә сөйләмдә сүзнең кулланылышын күрсәтә торган мисал китерелде. Мисал итеп кыска гына гыйбарәләр, гадәттә, киң кулланыла торган ирекле сүзтезмәләр, аерым очракларда әйтемнәр, мәкальләр, халык җырлары китерелде.

**ШИКӘРЛЕ** *сф.* 1) Шикәр салынган, татлы, баллы. *Шикәрле чәй*; 2) Табигый шикәре булган, татлы. *Шикәрле өрек.*

§32. Компонентлары аерым язылган кушма сүзләр һәм дәрәҗә белдерә торган тезмә фигыльләрнең телдә киң кулланылганнары, төп сүзгә аңлатма бирелгәч, турыпочмаклык (□) билгесеннән соң беренче сүз тәртибе белән теркәлде:

**ЮК** *хәб. сүз* 1) ... ; 2) ... . **Юк булу** 1) Кинәт югалу, күренми башлау; 2) Бөтенләй бетү, юкка чыгу. **Юкка чыгару** Бетерү, юк итү. **Юкка чыгу** Бөтенләй һәм эзсез бетү.

**УК|У** (-ы; -ый) *фг.* 1) ... ; 2) ... . **Укый төшү** Бераз уку. **Укып алу** Тиз генә, бераз уку. **Укып бару** 1) Язылган яки басылганны тоташтан уку; 2) Даими, системалы уку; һәрберсен уку. **Укып бетерү** Ахырына кадәр уку. **Укып бирү** Язылганны яки басылганны кемгә дә булса уку. **Укып йөрү** Берәр уку йортында уку, аның укучысы булу. **Укып китү** Берәр урыннан укый башлау. **Укып тору** 1) Хәзер, сөйләү моментында уку, уку белән шөгыльләнү; 2) Һәрвакыт, гел (*мәс.,* газета-журналны) уку. **Укып чыгу** Һәрберсен берәм-берәм, башыннан ахырына кадәр уку.

§33. Турыпочмаклык билгесе белән килгән кушма һәм тезмә сүзләрдән соң фразеологик берәмлекләрнең киң таралганнары ромб (◊) билгесеннән соң беренче сүз тәртибе белән китерелде:

**ИКЕНДЕ** (-гә; -дән; -се) *ис.* **1.** 1) Төштән соң һәрнәрсәнең күләгәсе үз озынлыгыннан ике тапкыр зур булган вакыттан алып кояш батканга кадәрге ара. *Икенде вакыты җитеп килә*; 2) *дини к.* **икенде намазы** □ **Икенде намазы** Мөселманнарда төштән соң кояш баеганчы дүрт рәкәгать укыла торган намаз (биш вакыт намазның өченчесе) ◊ **Икенде күләгәсе** Килбәтсез озын кеше.

§34. Фразеологик берәмлекләр сүзлекнең гомуми принципларына ярашлы рәвештә алынды. Мәгънәләре җәяле гарәп цифры белән аерылды. Аларга караган факультатив сүзләр гади җәя эчендә бирелде:

**ПӘРИ** (-гә; -дән; -е) *ис. миф.* 1) Җеннәрнең матур, гүзәл бер төре. *Пәри кебек гүзәл*; 2) *гади с. тирг.* ... ◊ **Пәрие килү (котыру, кузгалу)** 1) Берәр нәрсә белән бик нык мавыгу, шөгыльләнү; 2) Ачуланып, кызып китү.

§35. Кушма һәм тезмә сүзләргә, фразеологик берәмлекләргә мисаллар китерелмәде.

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*алм.* – алмашлык
*авиа.* – авиация
*анат.* – анатомия
*артык.* – артыклык дәрәҗәсе
*архит.* – архитектура
*астр.* – астрономия
*а.х.* – авыл хуҗалыгы термины
*әд.* – әдәбият термины
*бәйл.* – бәйлек
*бәйл. сүз* – бәйлек сүз
*б.э.к.* – безнең эрага кадәр
*биол.* – биология
*бор.* – борынгы сүз
*бот.* – ботаника
*бухг.* – бухгалтерия
*гади с.* – гади сөйләм
*геогр.* – география
*геол.* – геология
*геом.* – геометрия
*грам.* – грамматика
*диал.* – диалекталь сүз
*дини* – дини сүз
*җый. ис.* – җыйма исем
*җыр* – халык җыры
*зоол.* – зоология
*з-сыз* – затланышсыз (фигыль)
*иҗт.* – иҗтимагый
*инфор.* – информатика
*ирк.* – иркәләү сүзе
*ирон.* – ироник мәгънәдә
*ис.* – исем
*иск.* – искергән сүз
*иял. кил.* – иялек килеше
*иярт.* – ияртем
*йола* – йола атамасы
*йөкл. юн.* – йөкләтү юнәлеше
*к.* – кара
*каб.* – кабатлау дәрәҗәсе
*каб. форм.* – кабатлаулы формада
*карг.* – каргыш
*кер. сүз* – кереш сүз
*килеш* – килеш (формасында)
*кимл.* – кимлек дәрәҗәсе
*кимс.* – кимсетеп әйтү
*кис.* – кисәкчә
*кит.* – китап теле
*кулин.* – кулинария
*күпл.* – күплек сан
*күч.* – күчерелмә мәгънәдә
*лингв.* – лингвистика
*лог.* – логика
*мат.* – математика
*махс.* – махсус термин
*мәгъ.* – мәгънәдә, мәгънәсендә
*мәс.* – мәсәлән
*мед.* – медицина
*мех.* – механика
*миф.* – мифология
*мод. сүз* – модаль сүз
*муз.* – музыка
*мыск.* – мыскыллау сүзе
*пед.* – педагогика
*полигр.* – полиграфия
*рәв.* – рәвеш
*рәс.* – рәсми
*сан* – сан
*сәнг.* – сәнгать
*сәяси* – сәяси
*сир.* – сирәк кулланышта
*сөйл.* – сөйләү телендә
*спорт* – физкультура һәм спорт
*сф.* – сыйфат
*сын.* – сынлы сәнгать
*тар.* – тарихи
*тарт.* – тартымда төрләнгән
*тасв.* – тасвирый сәнгать
*тәрт. саны* – тәртип саны
*театр* – театр сәнгатенә караган сүз
*терк.* – теркәгеч
*тех.* – техника термины
*тирг.* – тиргәү сүзе
*туп.* – тупас сүз
*төш. кил.* – төшем килеше
*төш. юн.* – төшем юнәлеше
*урт. юн.* – уртаклык юнәлеше
*ур.-в. кил.* – урын-вакыт килеше
*фг.* – фигыль
*физ.* – физика
*физиол.* – физиология
*филос.* – философия

*фин.* – финанс
*фольк.* – фольклор
*форм.* – формасында, формада
*фото* – фотография
*функ.* – функция
*хим.* – химия
*хуплм.* – хупламау
*хупл.* –хуплау
*хур.* – хурлау
*хәб. функ.* – хәбәр функциясендә
*хәб. сүз* – хәбәрлек сүз
*хәрби* – хәрби
*чаг. дәр.* – чагыштыру дәрәҗәсе
*чыг. кил.* – чыгыш килеше
*шелт.* – шелтәләү сүзе
*шигъ.* – шигъри сөйләмдә
*ымл.* – ымлык
*эвф.* – эвфемизм
*энд.* – эндәш сүз
*экон.* – экономика
*этн.* – этнография
*юкл. форм.* – юклык формасында
*юг.* – югары стиль
*юн. кил.* – юнәлеш килеше
*юр.* – юридик термин
*ярд.* – ярдәмче (фигыль яки сүз)

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Аа | Ее | Йй | Оо | Уу | Чч | Ээ |
| Әә | Ёё | Кк | Өө | Үү | Шш | Юю |
| Бб | Жж | Лл | Пп | Фф | Щщ | Яя |
| Вв | Җҗ | Мм | Рр | Хх | Ъъ | |
| Гг | Зз | Нн | Сс | Һһ | Ыы | |
| Дд | Ии | Ңң | Тт | Цц | Ьь | |

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН СҮЗЛЕКЛӘР ИСЕМЛЕГЕ


Альфред Брем. Жизнь растений. Новейшая ботаническая энциклопедия. – М.: Эксмо, 2004.

Альфред Брем. Жизнь животных. Современная версия. – М.: Эксмо, 2004.

Амиров К.Ф. Русско-татарский юридический словарь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред.: А. Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.

Биологический русско-татарский толковый словарь / Сост.: Ф. Г. Ситдиков, Р. К. Закиев, А. Б. Халидов, И. Ш. Малеев и др. – Казань: Магариф, 1998.

Большой Российский энциклопедический словарь. – М.: Научное изд-во «Больш. Рос. энцикл.», 2005.

Вәлиди Җ. Татар теленең тулы сүзлеге: 2 кисәктә. – Казан, 1927–1929.

Галиев М. С., Тимергалин А. К. Русско-татарский словарь физических терминов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981.

Ганиев Ф. А., Гаффарова Ф. Ф. Русско-татарский словарь. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1996.

Гаффарова Ф. Ф., Саберова Г. Г. Татарско-русский словарь идиом / Под ред. Ф. И. Тагировой. – Казань, 2006.

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1989, 1990.

Ислам. Белешмә-сүзлек / Төз. З. Шәфигый. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

Краткий русско-татарский словарь исторических терминов / Сост. Г. И. Мустафина; науч. ред. Ж. С. Миннуллин. – Казань: КГПИ, 1993.

Мәхмүтов М. И. Русча-татарча мәктәп сүзлеге. – 3 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

Миннебаев М. М. Краткий русско-татарский толковый словарь медицинских терминов (с эквивалентами на английском, немецком, французском и латинском языках). – Казань: Медицина, 1994.

Насыйри К. Ләһҗәи татари: 2 томда. – Казан, 1895–1896.

Новый энциклопедический словарь / Гл. редактор А. П. Горкин. – М.: Научное изд-во «Больш. Рос. энцикл.», Изд-во «Рипол Классик», 2001.

Ожегов С.И. Словарь русского языка. – М.: Сов. энциклопедия, 1962.

Русско-татарский общественно-политический словарь / Сост.: Ф. А. Ганиев, И. М. Низамов и др.; Под рук. Р. М. Харисова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1997.

Русско-татарский словарь / Сост.: Э. М. Ахунзянов, Р. С. Газизов, Ф. А. Ганиев; под ред. Ф. А. Ганиева. – М.: Рус. яз., 1984.

Русско-татарский толковый терминологический словарь по агрохимии и почвоведению / Сост. М. Ю. Гилязов, С. Г. Муртазина, Ф. Ф. Гаффарова. – Казань: Магариф, 2004.

Русско-татарский толковый терминологический словарь по агроэкологии / Сост.: С. Г. Муртазина, М. Ю. Гилязов, Ф. Ф. Гаффарова, М. Г. Муртазин. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2008.

Татарско-русский словарь: в 2-х т. – Казань: Магариф, 2007.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда / Редкол.: Л. Т. Мәхмүтова, М. Г. Мөхәммәдиев, К. С. Сабиров, Ш. С. Ханбикова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977–1981.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 1 томда / Баш редакторы Ф. Ә. Ганиев. – Казан: Матбугат йорты, 2005.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

Татар халык мәкальләре: 3 томда / Җыючы һәм төз. Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959–1967.

Татар энциклопедия сүзлеге / Баш мөхәррир М. Х. Хәсәнов. – Казан: Татар. энц. ин-ты, 2002.

Татарско-русский словарь. – М.: Сов. энцикл., 1966.

Татарско-русский словарь / Сост.: И. А. Абдуллин, Ф. А. Ганиев, М. Г. Мухамадиев, Р. А. Юналеева; под ред. Ф. А. Га-ниева. – 4-е изд.– Казань: Татар. кн. изд-во, 2002.

Татарча-русча уку-укыту сүзлеге / Ф. Ә. Ганиев редакциясендә. – М.: Рус. яз., 1993.

Химический русско-татарский толковый словарь / Сост.: Г. Г. Хисамеев, А. И. Нарбеков, Н. Х. Амиров, И. А. Абдуллин, А. М. Галеев; ред. Г. Г. Хисамеев. – Казань: Магариф, 2004.

Справочное издание

**ШКОЛЬНЫЙ ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**

Казань. Татарское книжное издательство. 2013

На татарском языке

Белешмә басма

**ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ МӘКТӘПЛӘР ӨЧЕН АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ**

Мөхәррирләре *Н. К. Нотфуллина, Л. Р. Гатауллина, З. В. Шәйхразиева, Р. И. Раскулова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Г. С. Нуретдинова*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, С. З. Гыймалетдинова, А. М. Закирова, Г. Г. Мөхәммәтҗанова, Г. Р. Ногманова, Т. Н. Сәгъдуллина, А. А. Дәүләтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 30.10.2013.
Форматы 84×108 1/16. Шартлы басма табагы 53,76.
Тиражы 5000 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге.
Тел.: (843) 519-45-35.

Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете.
Тел.: (843) 292-03-18.

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының күргәзмә-кибете.
Тел.: (843) 519-45-13.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.